СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.11.2022 27-146

с. Нижний Услон

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең торак пункты территориясе өлешендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Ослан җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә Түбән Ослан авылы торак пунктының бер өлешенең халык төркеме инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясендә гражданнардан җыелган үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 30 ноябренә гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2023 елда Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Ленин урамыннан Чернышевский урамына кадәр сүүткәргеч төзү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Түбән Ослан авылы, Чернышевкий урамындагы 7нче йорт янында, 10.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын

оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В. Архиреев